**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның «22» июненнән № 238

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында нигезләмәне яңа редакциядә бәян итү хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 170 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында яңа редакциядәге нигезләмәне бәян итү хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 170 номерлы карары кушымтасының 1.4 пунктының 2 абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

- «тәэминатчыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү - заказчылар тарафыннан әлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган гамәлләр җыелмасы, дәүләт ихтыяҗларын (федераль ихтыяҗларны, Россия Федерациясе субъекты ихтыяҗларын) яки муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында хәбәр урнаштырудан башлап йә әлеге Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, тәэминатчыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашырга чакыру җибәргәннән соң, заказчылар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр җыелмасы һәм контракт төзү белән тәмамлана»;

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә

муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында яңа редакциядәге нигезләмәне бәян итү хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 170 номерлы карары кушымтасының 1.4 пунктының 3 абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

- «сатып алуда катнашучы - теләсә кайсы юридик зат, аның оештыру-хокукый формасына, милек рәвешенә, капиталның урнашу урынына һәм барлыкка килү урынына бәйсез рәвештә, теркәү урыны булып Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасы нигезендә расланган дәүләт яисә территория торган юридик заттан тыш, дәүләт яисә территориядән тыш, салым салуның ташламалы салым режимын һәм (яки) юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) уздырганда мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмаган теләсә кайсы физик зат (алга таба - офшорная компания), яисә теләсә кайсы физик зат, шул исәптән индивидуаль эшкуар сыйфатында теркәлгән;»;

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

ИНН 1631003397
ОГРН 1051650041740